КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 сентябрь г.Казань № 798

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның территориясендәге эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү юлы белән дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1185 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның территориясендәге эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү юлы белән дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1185 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә» сүзләрен «Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә» сүзләрен «Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның территориясендәге эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү юлы белән дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибендә:

исемендә «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә» сүзләрен «Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә» сүзләрен «Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктта:

беренче абзацта «һәм эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) иң чик кыйммәтеннән артмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидияләр смета документларын эшләүгә һәм смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауга бирелми.»;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәргә:

«з) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауның, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген (уңай бәяләмә) яки дөрес булмаганлыгын (тискәре бәяләмә) билгеләү турында бәяләмә.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин